| | |
| --- | --- |
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«17» 12 2021 ел № 387

«Балтач муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә ярдәм итү чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 186 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү хакында

«Социаль юнәлешле коммерциягә карамаган оешмалар реестры турында» 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карарының үз көчен югалтуын тану сәбәпле һәм Балтач районы прокуратурасының 2021 елның 13 декабрендәге 02-08-02-2021 номерлы протесты нигезендә Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. «Балтач муниципаль районында кече һәм урта эшкуарлык субъектларына аренда түләүләрен түләүдән азат итү өлешендә ярдәм итү чаралары турында» 2020 елның 25 маендагы 186 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

1.1. 1 пунктының «б» пунктчасын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә (baltasi.tatarstan.ru).

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов